**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге составына керүче Көрәш-Бүләк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**23.11.2020 ел** **№3**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»ГЫ 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2020 елның 23 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге составына керүче Көрәш-Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән , көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

- Көрәш-Бүләк торак пунктына керү юлын норматив хәлгә китерү, (төзелеш, реконструкция, асфальт, ремонт, вак таш җәю, ПГС җәю, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

-Көрәш-Бүләк торак пунктының, Совет урамы, Мәктәп урамы, юлларны норматив хәлгә китерү (төзелеш, реконструкция, асфальтлау, ремонт, вак таш, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)»соравы буенча.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 108 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 56 кеше катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында 56 катнашучы «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар чыгарды:

1 Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге Көрәш-Бүләк торак пунктында халык җыены узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2.Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге Көрәш-Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында

хезмәт итүчеләрдән тыш, 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме?:

- Көрәш-Бүләк торак пунктына керү юлын норматив хәлгә китерү, (төзелеш, реконструкция, асфальт, ремонт, вак таш җәю, ПГС җәю, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

-Көрәш-Бүләк торак пункты, Совет урамы, Мәктәп урамы буенча юлларны норматив хәлгә китерү (төзелеш, реконструкция, асфальтлау, ремонт, вак таш, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).- буенча сорауны кабул ителгән дип танырга.

3. Бәйрәкә-Тамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен халыкка игълан итәргә һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен юлларга.

Җыенда рәислек итүче
Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге башлыгы: Ф.В.Әхмәтов